| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА НОРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НОРМА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» декабрь 2025 г. № 19

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар уздыру турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында жирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач район Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләре турында» 2025 елнын 17 декабрендәге 28 нче номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегендә гавами тыңлаулар (жәмәгать фикер алышулары) үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 23 июне 169 нче номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлеге муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү турындагы мәсьәлә буенча фикер алышуда катнашу өчен гражданнарнын хокукларын үтәү максатларында, гавами тыңлаулар уздыру юлы белән **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балтач шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Норма авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча халык алдында тыңлаулар уздыруны кушымта итеп бирелә торган карта-схема (кушымта) нигезендә, 2026 елның 14 гыйнварына 11.00 сәгатькә Норма авыл җирлегенең авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адреста билгеләргә: ТР, Балтач районы, Норма авылы, Казанская ур., 1 йорт.

2. Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2026 елның 13 нче гыйнварына кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Норма авылы, М.Жәлил ур. 2А йорт, (Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Норма авыл җирлеге

башкарма комитеты административ бинасы), консультация өчен телефон: 8(843)68-3-15-10.

Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru), "ХЕЗМӘТ" басма-редакция газетасында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (https://baltasi.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлегенең:

- Норма авылы, М.Җәлил урамы , 2а нче йорт;
- Норма авылы, Казанская урамы, 1нче йорт;
- Кариле авылы, Г.Әшрәфҗанов урамы, 7 нче йорт;
- Кили авылы, Г.Тукай урамы , 33/3 нче йорт;
- Чапшар авылы, Х.Туфан урамы, 20/2 нче йорт;
- Пүскән авылы, Ф.Кәрим урамы, 22 нче йорт;
- Нормабаш авылы Г.Ибраһимов урамы, 25А нче йорт

буенча урнашкан мәгълүмат стендларында бастырып чыгару юлы белән халыкка житкерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Шарипҗанов

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль
районы Норма авыл
жирлеге башлыгының
25.12.2025 елдагы № 19
**карарына кушымта**

КАРТА-СХЕМА

